КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 24 апрель г.Казань № 337

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

«Верхнее Колчурино – Катюшино» автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII[1] бүлеге, 49 статьясы, Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Учреждение), Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Верхнеколчуринское авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, А.А.Мурзаков милкендә булган, 0,6510 гектар мәйданлы, 16:06:000000:859 кадастр санлы җир кишәрлеген (алга таба – җир кишәрлеге) Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

җир кишәрлеген алу турында карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Верхнеколчуринский авыл җирлеге уставы белән муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен Учреждениегә, А.А.Мурзаковка, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен каплау күләмен һәм мондый алу белән китерелә торган зыян күләмен билгеләүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә Учреждение белән берлектә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – җир кишәрлеген алу турында килешү) әзерләү һәм аны милекчегә җибәрү;

җир кишәрлекләрен алу турында килешүләр төзүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен түләүне;

алына торган җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлекләре милекчеләре тарафыннан имзалары куелган җир кишәрлекләрен алу турындагы килешүләр закон белән билгеләнгән вакытта тапшырылмаган очракта, судка тиешле исклар бирүне.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин